ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 июль 2019ел № 3548

Башкарма комитетның «Гражданнарның коммерцияле булмаган бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәсе әгъзасы булып торган гражданга җир участогын түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 31 июлендәге 4350 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гражданнар тарафыннан шәхси ихтыяҗлар өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ санлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 нчы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Гражданнарның коммерцияле булмаган бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәсе әгъзасы булып торган гражданга җир участогын түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 31 июлендәге 4350 нче карарына (Башкарма комитетның 2016 елның 22 июнендәге 3184 нче, 2018 елның 29 ноябрендәге 7118 нче карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемне яңа редакциядә бәян итәргә:

«Коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте әгъзасы булып торган гражданга җир участогын түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

2) 1, 2 пунктларда «гражданнарның коммерцияле булмаган бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәсе әгъзасы булып торган» сүзләрен «коммерцияле

булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте әгъзасы булып торган» сүзләренә алмаштырырга;

3) кушымтада:

- исемне яңа редакциядә бәян итәргә:

«Коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте әгъзасы булып торган гражданга җир участогын түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»;

- 1.1 пунктта «гражданнарның коммерцияле булмаган бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәсе әгъзасы булып торган» сүзләрен «коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте әгъзасы булып торган» сүзләренә алмаштырырга;

- 1.2 пунктта «гражданнарның коммерцияле булмаган бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәсе әгъзасы булып торган» сүзләрен «коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте әгъзасы булып торган» сүзләренә алмаштырырга;

- 2.5 пунктта:

4 пунктчада «гражданнарның коммерцияле булмаган берләшмәсе» сүзләрен «коммерцияле булмаган ширкәте» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. әлеге коммерцияле булмаган оешмада җир кишәрлекләрен бүлүне билгеләү турында 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3 маддәсе 2.7 пунктының беренче абзацында күрсәтелгән күрсәтелгән коммерцияле булмаган оешма әгъзаларының гомуми җыелышы беркетмәсе яки әлеге коммерцияле булмаган оешмада җир участокларын бүлүне билгели торган башка документ яисә күрсәтелгән беркетмәдән яки күрсәтелгән документтан өземтә»;

- 2.6 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе;<br>әлеге документлар белән эш итүче дәүләт | 1) Күчемсез милек объекты (ҖУ) турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;<br>2) Күчемсез милек объектының төп характеристикалары һәм аңа теркәлгән хокуклар турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;<br>3) Коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте әгъзаларының берсе дә элек милеккә җир участогы бирү турында гариза белән мөрәҗәгать итмәгән очракта, Башкарма комитет мөстәкыйль рәвештә түбәндәгеләрне соратып ала:<br>- мондый мәгълүматлар Бердәм дәүләт күчемсез милек | 137-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 2.8 пункты<br>218-ФЗ санлы Федераль законның 62 маддәсе |

| | | |
|---|---|---|
| органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | реестрында булган очракта, күчемсез милеккә хокукларны дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтләнгән федераль башкарма хакимият органындагы әлеге коммерцияле булмаган оешмага бирелгән җир участогына хокук билгеләүче документлар турында мәгълүматларны (башка очракларда мондый мәгълүматлар гариза бирүчедән соратып алына);<br>- күрсәтелгән коммерцияле булмаган оешма турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрында булган мәгълүматларны. | |

- 2.7 пунктта 2 пунктчаны төшереп калдырырга;

- 2.9 пунктта:

4 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«4) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир участогын бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килү (шундый гариза белән әлеге ширкәт әгъзасы (мондый җир участогы бакчачылык яки яшелчәчелек өчен исәпләнгән очракта) яисә гражданнар тарафыннан шәхси ихтыяҗлар өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территориясе чикләрендә урнашкан җир участоклары милекчеләре (җир участогы гомуми билгеләнештәге җир участогы булып исәпләнгән очракта) мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш);»;

- түбәндәге эчтәлектәге 4.1 пунктча белән тулыландырырга:

«4.1) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы индивидуаль торак төзелеше максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен коммерцияле булмаган оешмага бирелү (әгәр җир участогы әлеге оешманың гомуми файдалануындагы җир участогы булып торса, гариза белән әлеге оешма әгъзасы яисә әлеге оешма мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш);»;

14 пунктчада «дача хуҗалыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

17 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«17) коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтенә җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогының мәйданы РФ Җир кодексының 39.10 маддәсенең 6 пунктында билгеләнгән чик күләменнән артып китү;»;

3.5.3 пунктта «Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе (алга таба – архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе)» сүзләрен «Башкарма комитетның хокук идарәсе (алга таба – хокук идарәсе)» сүзләренә алмаштырырга;

3.5.4, 3.4.5 пунктларны төшереп калдырырга;

4) 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

5) 2 нче кушымтаны әлеге карарга 2 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

6) 3 нче кушымта һәм белешмә кушымтасы грифының исемнәрендә «гражданнарның коммерцияле булмаган бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәсе әгъзасы булып торган» сүзләрен «коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте әгъзасы булып торган» сүзләренә алмаштырырга;

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә имзаланган көннән башлап җиде көн срокта әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (htpp://pravo.tatarstan.ru) һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2019 елның 10 июлендәге
3548 нче карарына
1 нче кушымта

Коммерцияле булмаган бакчачылык яки
яшелчәчелек ширкәте әгъзасы булып
торган гражданга җир участогын түләүсез
бирү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ регламенты
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре
Башкарма комитеты
Җитәкчесе
_______________________________________________
_______________________________________________
(гражданның Ф.И.А.и.)
_______________________________________________
_______________________________________________
_______________________________________________
(гражданның паспорт мәгълүматлары)
_______________________________________________
_______________________________________________
_______________________________________________
(яшәү урыны адресы, элемтә өчен телефоннар)

ИНН ___________________________________________

## Гариза

Сездән, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 гыйнварындагы №137-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 2.7, 2.8 пунктлары нигезендә, Яр Чаллы шәһәре, ________________________________________________________ адресы буенча урнашкан, мәйданы _______ кв. м: кадастр номеры ___________________________________, № _____ җир кишәрлеген милеккә бирүегезне сорыйм.

Файдалану максаты – бакчачылык өчен.

Гаризага кушымта:

---

Гаризага кушымталар:


1. Физик зат булган гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) шәхесен раслаучы документ;
2. Гариза белән гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, физик зат вәкиленең хокукын (вәкаләтләрен) раслаучы документ күчермәсе;
3. Территориянең граждан тарафыннан әзерләнгән кадастр планында җир участогының урнашу схемасы. Чикләрендә җир участогы урнашкан территорияне межалау буенча расланган проект, коммерцияле булмаган ширкәт территориясен оештыру һәм төзү буенча расланган проект булганда яисә дәүләт күчемсез милек кадастрында мондый җир участогы чикләренең урнашу тасвирламасы булганда әлеге схеманы тапшыру таләп ителми;
4. Күрсәтелгән ширкәт әгъзалары арасында җир участокларын бүлү турында коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте әгъзаларының гомуми җыелышы (вәкилләр җыелышы) беркетмәсе, бу ширкәттә җир участокларын бүлүне билгели торган башка документ яки күрсәтелгән беркетмәдән яки күрсәтелгән документтан өземтә;
5. Җир участогына хокук билгеләүче документлар, әгәр аңа хокук күчемсез милек һәм аның белән килешүләр төзү хокукларының Бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса.


Гариза бирүченең имзасы______________
«_______» _______________20_________


Башкарма комитетның
2019 елның 10 июлендәге
3548 нче карарына
2 нче кушымта

Коммерцияле булмаган бакчачылык яки
яшелчәчелек ширкәте әгъзасы булып
торган гражданга җир участогын түләүсез
бирү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ регламенты
2 нче кушымта

## Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эзлеклелекнең блок-схемасы




ҖММИ бүлеге белгече кергән документлар нигезендә карар проектын әзерләүне гамәлгә ашыра һәм килешенү өчен ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрә
Башкарма комитетның милеккә җир участогы бирү турында карар проекты (алга таба – карар проекты)
Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында хат (алга таба – кире кагу турында хат)
ҖММИ бүлеге башлыгы карар проектын карап тикшерә, килешенә һәм аны килешенү өчен яисә кире кагу турындагы хатны имзалау өчен ҖММИ башлыгына җибәрә
ҖММИ башлыгына җибәрелгән карар проекты яисә кире кагу турында хат
ҖММИ бүлеге башлыгы карар проектын яисә кире кагу турындагы хатны карап тикшерә һәм:
- карар проектын килешенә һәм килешенү өчен архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә җибәрә;
- кире кагу турындагы хатны имзалый һәм әлеге хатны эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә
Имзаланган һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән кире кагу турында хат
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе бүлеге белгече кире кагу турында хатны терки һәм аны гариза бирүчегә җибәрә
Имзаланган һәм гариза бирүчегә җибәрелгән кире кагу туырнда хат
Хокук идарәсе карар проектын карап тикшерә, килешенә һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә яисә карар проектындагы кимчелекләр буенча күрсәтмә әзерли һәм әлеге кимчелекләрне бетерү өчен ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә
Килешенгән һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты
ҖММИ бүлеге белгече Хокук идарәсе күрсәткән карар проектындагы кимчелекләрне төзәтә һәм Хокук идарәсенә җибәрә




Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова